КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 18 ноябрь г.Казань № 1031

Тукай, Лениногорск муниципаль районнарында җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, «Җирләрне яки җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында» 2004 елның 21 декабрендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 6 нчы пунктына таянып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Тукай, Лениногорск муниципаль районнарында урнашкан 2,0149 гектар гомуми мәйданлы авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләрен кушымта нигезендә торбаүткәргеч транспорт объектларын урнаштыру максатларында сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшыру, телевидение, информатика җирләре, космос эшчәнлеген тәэмин итү җирләре, оборона, куркынычсызлык җирләре һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр категориясенә күчерергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 18 ноябрь, 1031 нче
карарына кушымта

Сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшыру, телевидение, информатика җирләре, космос эшчәнлеген тәэмин итү җирләре, оборона, куркынычсызлык җирләре һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр категориясенә күчерелә торган җир кишәрлекләре исемлеге

| Җир кишәрлегенең кадастр саны | Мәйданы, гектар | Муниципаль район исеме |
|---|---|---|
| 16:39:091201:282 | 0,9666 | Тукай |
| 16:39:091201:283 | 0,8071 | |
| 16:25:230311:184 | 0,209 | Лениногорск |
| 16:25:230311:185 | 0,0096 | |
| 16:25:230311:188 | 0,0098 | |
| 16:25:230311:187 | 0,0128 | |
| Барлыгы | 2,0149 | |

_______________________________________